СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » июнь 2025 ел. № 156

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 02.11.2023 ел, №517-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының 15.11.2010 № 13 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге башкарма комитеты турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 3.2.28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3.2.28. балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;».

1.2. 5 бүлегенең 5.5 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: «-чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгының туктатылуы, чит дәүләт гражданлыгының (гражданлыгының) йә яшәүгә рөхсәтенең яисә Россия Федерациясе гражданының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документының булуы, үзидарә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;";

1.3. 6.6 пунктның 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:: «-чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданлыгының туктатылуы, чит

дәүләт гражданлыгының (гражданлыгының) йә яшәүгә рөхсәтенең яисә Россия Федерациясе гражданының йә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документының булуы, үзидарә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Чепья авыл җирлеге башлыгы — А.Г. Нотфуллин